**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл жирлеге Советы**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ул. Советская, д.32г, с. Верхнее Стярле, 423314**
**Азнакаевского муниципального района**
**Тел.факс (8-85592) 42-6-18,**
**VSt..Azn@tatar.ru**

**Советурамы, 32г, Югары Стәрлеавылы, 423314**
**Тел.факс (8-85592) 42-6-18,**
**VSt.Azn@tatar.ru**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 31» январь 2023 г. № 1

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елнын 30 гыйнварендәге 119 номерлы карары нигезендә «2023 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2023 елның 01 февраленнән күмү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә 7 793,48 сум (җиде мең җиде йөз туксан өч сум 48 тиен) күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләргә һәм гамәлгә кертергә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә.

2. “2022 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенең иң чик күләмен раслау турында” 2022 елның 28 январендәге 5 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo. tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык Л.С.Сабирҗанова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге башкарма комитетынын 31.01..2023 елдагы № 1 карарына 1 нче кушымта.

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлектә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| **№** | **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум.** |
|---|---|---|
| 1 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3693,48 |
| 2 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1500,00 |
| 3 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2600,00 |
| **4** | **Барлыгы** | **7793,48** |

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Югары Стәрле авыл җирлеге башкарма комитетынын 31.01.2023 елдагы № 1карарына 2 нче кушымта

2023 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлектә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясенең чик күләме

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтүнең бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Кәфенләү | 1400,00 |
| 2 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 2293,48 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 1500,00 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2600,00 |
| **5** | **Барлыгы** | **7793,48** |